# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Саклаубаш авыл җирлегенең Өчиле-Саклау авылы торак пунктында гражданнар
җыены нәтиҗәләре турында

**от 14.11.2025 г.** **№ 1**

« Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы  33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә , "Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Саклаубаш авыл җирлеге Өчиле Саклау авылында 2026 нче елда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында» Сарман муниципаль районы Саклаубаш авыл җирлеге башлыгының 2025 елның 31 октябрендәге 4 номерлы карары нигезендә 2025 елның 14 ноябрендәге 13.00 сәгатьтә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән сораулар буенча гражданнар җыенының йомгаклау протоколы төзелде:

«Саклаубаш авыл җирлеге территориясендә Өчиле Саклау авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, I төркем инвалидларыннан тыш, 2026 елда үзара салым акчаларын кертүгә, вакытлы хәрби хезмәт үтүче гражданнардан, көндезге уку йортлары студентларыннан һәм алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрүгә килешәсезме?:

1) Өчиле Саклау торак пункты чикләрендә янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (янгын сүндерү гидранты кую)

2) Автомобиль юлларын карап тору өчен МТЗ-82.1 махсус техникасын карап тоту (ягулык-майлау материаллары, запчастьләр сатып алу, машина йөртүчегә хезмәт хакы түләү, вак таш җәю, юлларны кардан чистарту, үлән чабу);

3) Өчиле Саклау торак пунктына урам яктырту челтәрләрен ясау (лампалар сатып алу һәм алыштыру)

4) Өчиле Саклау торак пункт территориясен төзекләндерү (территорядәге үләннәрне чабу, килешү буенча эш һәм күрсәтелгән хезмәтләрне түләү)

5) Халыкның массакүләм ял итү урыннарын төзекләү (төзелеш материаллары сатып алу һәм ял паркы ясау) ?

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия булган _130__ кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны - _81___ кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
гражданнар җыенында «РИЗА» позициясе өчен _81___катнашучы тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен  ____0___ катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар итте:

1. Сарман муниципаль районының Саклаубаш авыл жирлегенең Өчиле-Саклау авылы торак пунктында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыены нәтиҗәләрен гамәлдә дип танырга.

2. «Саклаубаш авыл җирлеге территориясендә Өчиле Саклау авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, I төркем инвалидларыннан тыш, 2026 елда

үзара салым акчаларын кертүгә, вакытлы хәрби хезмәт үтүче гражданнардан, көндезге уку йортлары студентларыннан һәм алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрүгә килешәсезме?:

1) Өчиле Саклау торак пункты чикләрендә янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (янгын сүндерү гидранты кую)

2) Автомобиль юлларын карап тору өчен МТЗ-82.1 махсус техникасын карап тоту (ягулык-майлау материаллары, запчастьләр сатып алу, машина йөртүчегә хезмәт хакы түләү, вак таш җәю, юлларны кардан чистарту, үлән чабу);

3) Өчиле Саклау торак пунктына урам яктырту челтәрләрен ясау (лампалар сатып алу һәм алыштыру)

4) Өчиле Саклау торак пункт территориясен төзекләндерү (территорядәге үләннәрне чабу, килешү буенча эш һәм күрсәтелгән хезмәтләрне түләү)

5) Халыкның массакүләм ял итү урыннарын төзекләү (төзелеш материаллары сатып алу һәм ял паркы ясау); мәсьәләсе буенча карарны кабул ителгән дип танырга

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Саклаубаш авыл җирлегенең мәгълүмати стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (http:/ https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Саклаубаш авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Сарман муниципаль районы
Саклаубаш авыл җирлеге башлыгы,
Халык җыенында рәислек итүче Л.М.Габидуллина